КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2018 ел, 7 ноябрь | г.Казань | № 983

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер норматив хокук актларына үзгәрешләр кертү турында

«Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге ФЗ-392 номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 18 август, 409 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 23 ноябрь, 1020 нче; 2015 ел, 1 июнь, 396 нчы; 2018 ел, 12 июль, 566 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.59 нчы пунктчада «сыйфатын» сүзе алдыннан «шартлары» сүзен өстәргә;

3.3.60 һәм 3.3.61 нче пунктчаларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.60. Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслый.

3.3.61. Түбәндәгеләрне урнаштыра:

мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта;

Мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.»;

3.3.62 нче пунктчада «сыйфаты» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче; 2015 ел, 17 сентябрь, 684 нче; 2015 ел, 14 октябрь, 767 нче; 2015 ел, 22 декабрь, 984 нче; 2016 ел, 31 март, 186 нчы; 2016 ел, 22 июль, 501 нче; 2017 ел, 8 май, 266 нчы; 2017 ел, 13 июнь, 375 нче; 2017 ел, 19 июнь, 390 нчы; 2017 ел, 31 август, 623 нче; 2017 ел, 26 сентябрь, 720 нче; 2018 ел, 15 февраль, 89 нчы; 2018 ел, 11 июнь, 448 нче; 2018 ел, 20 август, 675 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.11 нче пунктчада:

унөченче абзацта «сыйфатын» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

ундүртенче абзацта «сыйфаты» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы аларның гамәлгә куючылары булган социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар, шулай ук социаль хезмәтләрне Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән күрсәтә торган дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Министрлык каршындагы Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.».

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы мәсьәләләре» 2009 ел, 8 май, 287 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 19 май, 388 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1040 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2012 ел, 7 март, 195 нче; 2012 ел, 10 октябрь, 844 нче; 2013 ел, 19 март, 193 нче; 2013 ел, 18 июль, 501 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 859 нчы; 2014 ел, 23 гыйнвар, 30 нчы; 2014 ел, 22 октябрь, 773 нче; 2015 ел, 11 июнь, 426 нчы; 2017 ел, 16 март, 148 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1072 нче; 2018 ел, 8 август, 643 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан

Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 нче пунктта:

җитмеш икенче – җитмеш дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен федераль законнар нигезендә шартлар тудыра;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслый;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыра;»;

җитмеш бишенче абзацта «сыйфаты» сүзе алдына «гамәлгә ашыру шартлары» сүзләрен өстәргә, татарча текстта «эшчәнлеге» сүзен «эшчәнлеген» сүзенә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра.».

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турында» 2010 ел, 18 ноябрь, 906 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 15 октябрь, 856 нчы; 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче; 2014 ел, 20 сентябрь, 669 нчы; 2015 ел, 14 май, 341 нче; 2015 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2015 ел, 17 ноябрь, 862 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 781 нче; 2018 ел, 24 август, 708 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы министрлыгы, дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы иҗтимагый совет турындагы бертип нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 нче пунктның дүртенче абзацы, 2.2 нче пунктның алтынчы абзацы һәм 2.4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче; 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы; 2015 ел, 26 август, 623 нче; 2016 ел, 17 октябрь, 749 нчы; 2016 ел, 31 октябрь, 800 нче; 2017 ел, 10 май, 269 нчы; 2018 ел, 30 июль, 613 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3.48 нче пунктта «сыйфатын» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

3.3.49 һәм 3.3.50 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.49. Медицина оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау.

3.3.50. Түбәндәгеләрне урнаштыра:

медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта;

Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет эшчәнлеге турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында.»;

3.3.51 нче пунктта «сыйфаты» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә.

6. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль өлкә тармакларында мәдәният өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр» чаралар планы («юл картасы») турында» 2013 ел, 4 апрель, 227 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 апрель, 299/1 нче; 2013 ел, 30 апрель, 299/2 нче; 2014 ел, 14 июль, 494 нче; 2015 ел, 5 июнь, 419 нчы; 2016 ел, 9 июль; 469 нчы; 2016 ел, 23 декабрь, 981 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Социаль өлкә тармакларында мәдәният өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр» чаралар планына («юл картасына») түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрүгә юнәлдерелгән, нәтиҗәле контрактка күчүгә бәйле булган төп чаралар» дигән V бүлекнең таблицасында:

«Мәдәният учреждениеләренең эш сыйфатын бәяләү буенча бәйсез система һәм тикшерүдә тоту нигезендә мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү сыйфатын яхшырту» бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәдәният оешмаларының хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм тикшерүдә тоту нигезендә мәдәният өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын яхшырту»;

24 нче пунктта 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Республикада мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне (алга таба – бәйсез бәяләү) тормышка ашыру эшен яраштыруны тәэмин итү»;

25 нче пунктны төшереп калдырырга;

26 нчы пунктта 2 графада «учреждениеләрнең эш сыйфатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

28 нче пунктта:

2 графада «мәдәният учреждениеләре сыйфатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

3 графада «учреждениеләрнең эш» сүзләрен «мәдәният оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартларын» сүзләренә алыштырырга;

29 нчы пунктта:

2 графада «Мәдәният учреждениеләренең эш сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасы» сүзләрен «Бәйсез бәяләү» сүзләренә алыштырырга;

3 графада «бәяләүнең бәйсез системасын» сүзләрен «бәйсез бәяләүне» сүзләренә алыштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2013 ел, 29 май, 359 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 сентябрь, 701 нче; 2014 ел, 30 июнь, 450 нче; 2016 ел, 29 гыйнвар, 46 нчы; 2016 ел, 30 декабрь, 1060 нчы; 2017 ел, 18 февраль, 101 нче; 2017 ел, 27 март, 187 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планына («юл картасына») түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлектә:

1.5 нче пунктта:

утыз дүртенче абзацта «күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең сыйфатын бәйсез бәяләү» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү» сүзләренә алыштырырга;

утыз бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү функцияләре Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм Татарстан Республикасы аларның гамәлгә куючылары булган социаль хезмәт күрсәтүче оешмалар, шулай ук социаль хезмәтләрне Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән күрсәтә торган дәүләткә карамаган социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча Министрлык каршындагы Иҗтимагый советка йөкләнгән;»;

утыз алтынчы абзацта «җыю, гомумиләштерү һәм анализлауны» сүзләрен «җыю һәм гомумиләштерүне» сүзләренә алыштырырга, «сыйфаты» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

утыз җиденче – утыз сигезенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгълүмат ачыклыгын тәэмин итү өчен Министрлыкның рәсми сайтында махсус бүлек булдырылган, анда социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне формалаштыру буенча мәгълүмати һәм норматив документлар урнаштырылган;

социаль хезмәтләрдән файдаланучылар фикерен белдерү өчен социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында үз фикерен белдерергә мөмкин булган бүлек булдырылган. Әйтелгән тәкъдимнәрне анализлау социаль хезмәтләр күрсәтү шартларын яхшырту өчен кулланыла.»;

3 нче пунктның 7 нче пунктчасында «хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләүнең бәйсез системасын» сүзләрен «хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү» сүзләренә алыштырырга;

III бүлекнең таблицасында:

5.8 нче пунктта «хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү» сүзләрен «хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү» сүзләренә алыштырырга, татарча текстта «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга;

5.9 нчы пунктта 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне тормышка ашыруны мәгълүмати тәэмин итү, шул исәптән:

социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү;

социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү эшчәнлеге турындагы мәгълүматны рәсми сайтта урнаштыру;

оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен рәсми сайтта урнаштыру»;

5.10 нчы пунктта «оешмаларның эш сыйфатын бәяләү нәтиҗәләре буенча иҗтимагый совет» сүзләрен «социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый совет» сүзләренә алыштырырга.

8. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Аерым оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру чаралары турында» 2013 ел, 24 октябрь, 793 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 14 май, 341 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «сыйфатын» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф, мәдәният, гражданнарның сәламәтлеген саклау, социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатын яхшырту, шулай ук «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге ФЗ-256 нчы Федераль законны, «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге ФЗ-392 номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

3 – 6 нчы пунктлар үз көчен югалткан дип санарга;

7 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.».

9. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 март, б-557 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 10 март, б-462 нче; 2014 ел, 30 июль, б-1467 нче; 2015 ел, 24 март,

б-474/1 нче; 2017 ел, 16 гыйнвар, б-46 нчы; 2017 ел, 28 апрель, б-838 нче; 2018 ел, 26 апрель, б-981 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасында социаль өлкә тармакларындагы сәламәтлек саклау нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр» (2013 – 2018 еллар) чаралары планына («юл картасы»на) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

«Медицина ярдәме сыйфатын бәяләү буенча бәйсез система чаралары» бүлекчәсе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү буенча чаралар»;

17 нче пунктта:

2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү (алга таба – бәйсез бәяләү) үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру»;

5 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын яхшырту»;

18 нче пункттагы 2 графада «Сыйфатны бәяләүнең бәйсез системасын» сүзләрен «Бәйсез бәяләү» сүзләренә алыштырырга;

19 нчы пунктта:

2 графада «Медицина оешмалары эше сыйфатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

5 графада «Медицина оешмалары эше сыйфатын» сүзләрен төшереп калдырырга;

21 нче пунктта 2 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Медицина оешмалары эшенә мониторинг үткәрү һәм кабул ителгән норматив һәм методик документлар нигезендә аларның эшчәнлекләре рейтингларын төзү, бәйсез бәя бирүне формалаштыру.»;

22 нче пунктта 2 графада «социаль хезмәтләр күрсәтүче оешмаларның эш сыйфатына» сүзләрен төшереп калдырырга.

10. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 апрель, б-602 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 нче пунктның «а» пунктчасындагы бишенче абзацта « дәүләт учреждениеләре эшчәнлеген бәяләүнең башка критерийлары» сүзләреннән соң «, мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә дәүләт оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре» сүзләрен өстәргә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 26 декабрь, б-3598 нче боерыгына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгариф, мәдәният, гражданнарның сәламәтлеген саклау, социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартларының сыйфатын яхшырту, шулай ук «Мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон

актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 21 июлендәге ФЗ-256 нчы Федераль законны, «Мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге ФЗ-392 номерлы Федераль законны тормышка ашыру максатларында:»;

1 нче пунктта «сыйфатын» сүзе алдына «шартлары» сүзен өстәргә;

әлеге боерык белән расланган 2021 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасында мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрүне оештыру буенча чаралар планын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

12. Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

15 эш көне эчендә мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый советлар оештыру инициативасы белән чыгуны һәм алар турындагы нигезләмәләрне раслауны;

Татарстан Республикасы министрлыклары каршындагы иҗтимагый советлар карарлары нигезендә мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү өлешендә эшләрне мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый советларга тапшыруны оештыруны;

ел саен Россия Федерациясенең дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр башкаруны, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнары нигезендәмәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфаты турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерү буенча эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә дәүләт контрактларын төзүне;

мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрелгән оешма җитәкчеләренә ирештерүне;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органына тапшырыла торган мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы Россия Федерациясе субъектының иң югары вазыйфаи затының (Россия

Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенең) мәҗбүри гавами хисап формасын һәм мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү һәм федераль медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планы формаларын раслау хакында» 2018 елның 17 апрелендәге 457 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 457 номерлы карары) белән расланган форма буенча мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча оешмалар планнарын әзерләүне һәм раслауны;

мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча күрелә торган чаралар турындагы мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтларында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыруны;

мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү үткәрү буенча иҗтимагый советлар эшчәнлеге турындагы мәгълүматны үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларында урнаштыруны;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта сыйфатны бәйсез бәяләү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматның дөреслеген, тулылыгын һәм аны үз вакытында урнаштыруны тәэмин итүче җаваплы вазыйфаи зат билгеләүне;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтка гражданнар керү һәм аларның аларның бәяләмәләре, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү эшен оештыру мониторингын алып баруны һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта гражданнарга кабул ителгән чаралар турында хәбәр итүне;

хисап елыннан соң килүче елның 15 февраленә кадәр ел саен эшчәнлекнең тиешле өлкәсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 457 нче карары белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертелә торган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан һәм гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре һәм әлеге оешмаларның эшчәнлеген камилләштерү буенча кабул ителә торган чаралар турындагы мәҗбүри гавами хисапны (алга таба – мәҗбүри гавами хисап) формалаштыру өчен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының

Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына хисап кертүне;

15 эш көне эчендә мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрелгән ведомство карамагындагы дәүләт оешмалары җитәкчеләре эшенең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә мәдәният, социаль хезмәт күрсәтү, сәламәтлек саклау һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү һәм мондый бәяләү барышында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү планын үтәү нәтиҗәләрен бәяли торган күрсәткечне өстәү өлешендә дәүләт оешмалары җитәкчеләре белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 8 апрель, б-602 нче боерыгының 2 пункты нигезендә расланган дәүләт учреждениеләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү критерийларын билгеләү турындагы норматив хокукый актларга, хезмәт шартнамәләренә үзгәрешләр кертүне.

13. Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә, түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

ел саен, агымдагы елның 30 мартына кадәр, мәҗбүри гавами хисапны әзерләүне һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрүне;

мәҗбүри гавами хисапны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында һәм дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр турында мәгълүмат урнаштыру өчен рәсми сайтта урнаштыруны оештыруны.

14. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә белем бирү, мәдәният, гражданнарның сәламәтлеген саклау, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне оештыру эшчәнлеген оештыру-методик һәм мәгълүмати яктан тәэмин итүне гамәлгә ашырырга.

15. Җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

мәгариф, мәдәният, гражданнарның сәламәтлеген саклау, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәтләр күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне гамәлгә ашыру буенча шундый ук карарлар кабул итүне;

ел саен, хисап елыннан соң килүче елның 15 февраленә кадәр, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештереп, Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгына мәҗбүри гавами хисапны формалаштыру өчен хисап кертүне.

16. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин